МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

28.11.2016 № 510

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары Исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.02.2016 № 119 «Халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы 2004 елның 8 декабренең № 62-ТРЗ «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» законы, 1994 елның 21 декабренең № 68-ФЗ «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Федераль законы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы С.В. Хәлиловка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгында дәүләт теркәве эшен оештырырга һәм аны рус һәм татар телләрендә Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының эшләр белән идарә итүчесе А.В. Молевка Административ регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми

порталының Татарстан Республикасы ГТХМ субпорталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкны тарату бите нигезендә вазыйфаи затларга җиткерергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
гражданнар оборонасы һәм
гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының
28.11.2016 ел № 510 Боерыгына
Кушымта

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле
Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм
гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары
Исемлеге

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының (алда - Кодекс) 28.3 статьясының 2 нче өлешенең 7 нче пункты, 28.3 статьясының 4 нче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының түбәндәге вазыйфаи затлары Кодексның 20.6 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы:

министр урынбасары (халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге мәсьәләләре эшен күзәтче);

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең баш белгече;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең I категория белгече;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең бүлекчәсе башлыгы;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге бүлекчәсенең гражданнар оборонасы белгече (төп белгеч).